**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**с. Тюлячи**

**КАРАР**

«16» январь 2023г.

№ 2

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 6 февралендәге 48 номерлы «Теләче муниципаль районы муниципаль мәгариф учреждениеләрендә эшләүче педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү бирү Тәртибен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

МКУ «Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге»нең 2023 елның 13 гыйнварындагы 7 номерлы хатын карап, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә айлык өстәмә түләүләр билгеләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 29 декабрендәге 1270 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 ноябрендәге 1214 номерлы карары нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 6 февралендәге 48 номерлы «-Теләче муниципаль районы муниципаль мәгариф учреждениеләрендә эшләүче педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү бирү Тәртибен раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- күрсәтелгән карар белән расланган Теләче муниципаль районы муниципаль мәгариф учреждениеләрендә эшләүче педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү бирү Тәртибенә:

А) 3 пунктта «30 яшькә кадәр» сүзләрен «35 яшькә кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

Б) 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү белем бирү эшчәнлеген башкаручы оешмаларның педагогик хезмәткәрләре вазыйфаларының, мәгариф оешмалары җитәкчеләре вазыйфаларының Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның педагогик хезмәткәрләре вазыйфалары номенклатурасын раслау турында» 2022 елның

21 февралендәге 225 номерлы карары белән расланган номенклатурасының 1 бүлегендәге 2 пункт нигезендә билгеләнә».»;

В) 14 пунктта:

- дүртенче абзацта «1 111 сум» сүзләрен «2 510 сум» сүзләренә алмаштырырга;

- бишенче абзацта «1 111 сум» сүзләрен «2 510 сум» сүзләренә алмаштырырга;

Г) 15 пунктта:

- дүртенче абзацта «1 111 сум» сүзләрен «2 510 сум» сүзләренә алмаштырырга;

- бишенче абзацта «1 111 сум» сүзләрен «2 510 сум» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин